# КАРАР

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Ике басу Арташ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

08.09.2022 №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Арташ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Арташ авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 25 октябрендәге 22 номерлы карары нигезендә, 2023 нче елда Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге Ике басу Арташ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1 Ике басу Арташ пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге чокырларны ямау, вак таш белән капларга (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) дигән сорау буенча 2022 нче елның 08 нче сентябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре буенча җыен беркетмәсе төзелде

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 236 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 122 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _122_е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Арташ авыл җирлегенең Ике басу Арташ торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2023 нче елда Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге Ике басу Арташ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Ике басу Арташ пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге чокырларны ямау, вак таш белән капларга (сатып алу, ташу, вак таш салу, килешү буенча эшләр өчен түләү) дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Җыен нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында: https://saby.tatar.ru/artash адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Арташ авыл җирлеге башлыгы А.Р. Әгъләмҗанов